**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2026 елның 25 феврале 272/ПИК

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында хезмәтне саклау һәм техника иминлеге нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә җаваплы затларны беркетү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025елның 29 декабрендәге 2503/ПИК карары белән расланган «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» программасын үтәү йөзеннән, карар бирәм:

1. Хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау буенча Координация советы әгъзалары составыннан хезмәтне саклау һәм техника иминлеге нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә җаваплы затларны беркетергә:

| | | |
|---|---|---|
| - Карсалова Г.Н. | - | муниципаль учреждениеләрдә; |
| - Солягин А.О. | - | социаль өлкә учреждениеләрендә; |
| - Шитов И.П. | - | төзелеш предприятиеләрендә һәм төзелеш индустриясе предприятиеләрендә; |
| - Ильясов И.Т. | - | сәнәгать өлкәсе предприятиеләрендә; |
| - Гыйниятуллин Р.Г. | - | торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрендә; |
| - Германов В.В. | - | авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә. |

2. Җаваплы затларга беркетелгән предприятиеләрдә хезмәтне саклау һәм техника иминлеге нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүне даими күзәтеп торырга.

3. «Лаеш муниципаль районында хезмәтне саклау һәм иминлек техникасы нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә җаваплы затларны беркетү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025елның 14 ноябрендәге 2149/ПИК номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Т. Гарифуллин